**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№ 4722**
**24.08.2018**

Бөтенроссия Спортның ишегалды төрләре көненә
һәм Яр Чаллы шәһәренең 88 еллыгына багышланган
спортның ишегалды төрләре фестивален үткәрү турында

Сәламәт яшәү рәвешен һәм «ГТО» комплексын популярлаштыру, шәһәр микрорайоннарында физкультура ялын үстерү, спорт традицияләрен яңарту, шәһәр халкында физик культураны гомуми милли культураны тәшкил итүче буларак формалаштыру максатында, шәһәр Уставының 41 маддәсе, Шәһәр Советының 2014 елның 17 апрелендәге 30/18 нче карары белән расланган «Яр Чаллы шәһәрендә территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибе, Башкарма комитетның 2017 елның 27 октябрендәге 6519 нчы карары белән расланган «2018-2020 елларга Яр Чаллы шәһәренең территориаль иҗтимагый үзидарәсен үстерү» муниципаль программасы нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Бөтенроссия Спортның ишегалды төрләре көненә һәм Яр Чаллы шәһәренең 88 еллыгына багышланган спортның ишегалды төрләре фестивален (алга таба – фестиваль) 2018 елның 8 сентябрендә үткәрергә.

2. Расларга:

1) фестивальне әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитеты составын, 1 нче кушымтада каралганча;

2) фестиваль үткәрү турында нигезнамәне, 2 нче кушымтада каралганча.

3. Башкарма комитетның финанс идарәсенә фестивальне оештыру һәм үткәрү чыгымнарын финанслауны 2018 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетының «Төзекләндерү» 05.03 бүлегендә (бүлекчәсендә) каралган акчалар хисабына 50 000 (илле мең сум) күләмендә, 3 нче кушымтада каралганча тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка, Башкарма комитетның район Хакимиятләре Башлыклары И.Н. Галимовка, А.И. Кисловка, Р.М. Усмановага, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2018 елның 24 августындагы
4722 нче карарына
1 нче кушымта

Бөтенроссия Спортның ишегалды төрләре көненә һәм Яр Чаллы шәһәренең 88 еллыгына багышланган спортның ишегалды төрләре фестивален әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитеты
составы

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Зуев И.С. | - оештыру комитеты рәисе, Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары |
| 2. | Хәлимов Р.М. | - оештыру комитеты рәисе урынбасары, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары |
| комитет әгъзалары: | | |
| 3. | Айдимирова О.В. | - Комсомол районы Территориаль иҗтимагый үзидарәне үстерүгә ярдәм күрсәтү ассоциациясенең идарә рәисе (килешенү буенча) |
| 4. | Галимов И.Н. | - Башкарма комитетның Үзәк районы Хакимияте Башлыгы |
| 5. | Кислов А.И. | - Башкарма комитетның Комсомол районы Хакимияте Башлыгы |
| 6. | Мөхәммәтҗанова Р.Р. | - Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсе башлыгы |
| 7. | Мөхәммәтҗанова М.Я. | - Үзәк районы Территориаль иҗтимагый үзидарәне үстерүгә ярдәм күрсәтү ассоциациясенең идарә рәисе (килешенү буенча) |
| 8. | Насрединов Р.М. | - Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе башлыгы |
| 9. | Наумкина В.М. | - Автозавод районы Территориаль иҗтимагый үзидарәне үстерүгә ярдәм күрсәтү ассоциациясенең идарә рәисе (килешенү буенча) |
| 10. | Усманова Р.М. | - Башкарма комитетның Автозавод районы Хакимияте Башлыгы |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова

Башкарма комитетның
2018 елның 24 августындагы
4722 нче карарына
2 нче кушымта

Бөтенроссия Спортның ишегалды төрләре көненә һәм Яр Чаллы шәһәренең 88 еллыгына багышланган спортның ишегалды төрләре фестивален үткәрү турында
нигезнамә

1 бүлек. Максатлары һәм бурычлары

1. Бөтенроссия Спортның ишегалды төрләре көненә һәм Яр Чаллы шәһәренең 88 еллыгына багышланган спортның ишегалды төрләре фестивале (алга таба – фестиваль) түбәндәге максатларда үткәрелә:
1) сәламәт яшәү рәвешен һәм «ГТО» комплексын популярлаштыру;
2) шәһәр микрорайоннарында физкультура ялын үстерү;
3) спорт традицияләрен яңарту;
4) шәһәр халкында физик культураны гомуми милли культураны тәшкил итүче буларак формалаштыру.
2. Фестиваль үткәрүнең төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:
1) территориаль иҗтимагый үзидарәне үстерү һәм аңа ярдәм күрсәтү;
2) шәһәр территориясендә яшәүче гражданнарны системалы рәвештә физкультура һәм спорт белән шөгыльләнүгә җәлеп итү;
3) шәһәр халкына массакүләм физкультура-спорт хәрәкәте өчен шартлар тудыру;
4) массакүләм физкультура-спорт эшен оештыру формаларын камилләштерү.

2 бүлек. Фестивальне үткәрү сроклары һәм урыны

3. Фестиваль 2018 елның 8 сентябрендә 14.00 сәгатьтә «Виктория» балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе» өстәмә белем бирү учреждениесе» МАУ спорт базасында үткәрелә.
4. Фестивальнең программасы:
13.30-13.50 – катнашучыларны теркәү;
14.00-14.15 – рәсми ачылу тантанасы;
14.15-16.00 – спорт төрләре буенча ярышлар;
16.15-16.30 – ярышларның җиңүчеләрен бүләкләү тантанасы.

3 бүлек. Фестивальне үткәрү шартлары

5. Фестиваль спорт төрләре буенча спорт ярышлары, шулай ук спорт бәйгеләре рәвешендә оештырыла. Аларга гомуми физик, интегратив-комплекслы хәрәкәт юнәлешендәге, катнашучыларны тизлеккә, көчкә, тизлек-көч

сыйфатларына, чыдамлыкка, җитезлеккә, координациягә сынау буенча йөкләнешләр кирә.

6. Фестивальдә шәһәрнең территориаль иҗтимагый үзидарәләренең шәһәрдә яшәүчеләрдән торган җыелма командалары катнаша. Бер территориаль иҗтимагый үзидарәдән 1 команда күрсәтелә.

7. Бер катнашучы ике төрдән дә артык ярышларда катнаша алмый.

8. Командада катнашучыларның тиешле спорт формасы кия.

9. Ярышларда катнашуга каршы килә торган медицина күрсәткечләре булган затка фестивальдә катнашу рөхсәт ителми.

10. Фестиваль үткәрү кысаларындагы ярышлар түбәндәге программа нигезендә үткәрелә:

| Т/с | Ярышларның төре | Үсеш төркеме | Җенесе | Кеше саны |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Шахматлар | 35 яшьтән өлкән | 1 ир-ат | 1 |
| 2. | Шашкалар | 35 яшьтән өлкән | 1 хатын-кыз | 1 |
| 3. | Армреслинг | 35 яшьтән өлкән | 1 ир-ат,<br>1 хатын-кыз | 2 |
| 4. | Гер спорты | 25 яшьтән өлкән | 1 ир-ат | 1 |
| 5. | Скакалкада сикерү | 35 яшьтән өлкән | 1 ир-ат,<br>1 хатын-кыз | 2 |
| 6. | «ГТО нормаларын тапшыру»:<br>- урыннан озынлыкка сикерү | 35 яшьтән өлкән | 1 ир-ат,<br>1 хатын-кыз<br>. | 2 |
| | - кулда күтәрелү | | | |
| | - яткан килеш гәүдәне күтәрү | | | |
| | - алга иелү | | | |
| | - 30 м. яки 60 м.га йөгерү | | | |
| 7. | Дартс | 35 яшьтән өлкән | 1 ир-ат,<br>1 хатын-кыз | 2 |
| 8. | Гаилә эстафетасы | 2 өлкән кеше + 1 бала<br>(7-10 яшь) | 1 ир-ат.<br>1 хатын-кыз, бала | 3 |

## 4 бүлек. Фестиваль үткәрүне оештыру һәм аңа җитәкчелек итү

11. Фестиваль үткәрүне оештыруны һәм аңа гомуми җитәкчелек итүне Башкарма комитетның физкультура һәм спорт идарәсе Башкарма комитетның район Хакимиятләре һәм шәһәр районнарының Территориаль иҗтимагый үзидарәне үстерүгә ярдәм күрсәтү ассоциацияләре белән берлектә гамәлгә ашыра.

12. Фестивальне әзерләү һәм үткәрү өчен составы Башкарма комитет карары белән раслана торган оештыру комитеты төзелә. Оештыру комитеты фестивальнең судьялар коллегиясен формалаштыра.

## 5 бүлек. Йомгак ясау һәм җиңүчеләрне бүләкләү

13. Җиңүчеләр дип танылалар:

– күбрәк сандагы баллар җыйган һәм ярышларның һәр төрендә 1, 2, 3 нче призлы урыннарны алган катнашучылар/командалар;

– барлык төр ярышларның йомгаклары буенча 1, 2, 3 нче призлы урыннарны алган территориаль иҗтимагый үзидарә командалары.

14. 1, 2, 3 нче призлы урыннар алган катнашучылар/командалар дипломнар һәм истәлекле призлар белән бүләкләнә.

15. Кубок барлык төр ярышларның йомгаклары буенча 1, 2, 3 нче призлы урыннарны алган территориаль иҗтимагый үзидарә командаларына тапшырыла.

16. Йомгак ясалганда, составында 10 һәм аннан да артыграк кеше булган командалар өстәмә 2 балл алалар.

## 6 бүлек. Заявкалар

17. Фестивальдә катнашуга территориаль иҗтимагый үзидарә рәисе тарафыннан имзаланган, командадагы катнашучыларның шәхси имзасы куелган заявкалар судьялар коллегиясенә 2018 елның 3 сентябренә кадәр түбәндәге форма буенча бирелә:

Спортның ишегалды төрләре фестивалендә катнашуга
________________________________ районы
ТИҮ нән заявка «__________»

| Т/с | Командада катнашучыларның Ф.И.А.и. | Адресы (комплекс буенча), телефоны | Туган көне | Яше | Ярышларның төре | Гомерем һәм сәламәтлегем өчен шәхсән җавап бирәм (шәхси имза) |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. | | | | | | |
| 2. | | | | | | |

Җаваплы вәкилнең Ф.И.А.и., элемтә телефоны ________________

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова

Башкарма комитетның
2018 елның 24 августындагы
4722 нче карарына
3 нче кушымта

Бөтенроссия Спортның ишегалды төрләре көненә һәм Яр Чаллы шәһәренең 88 еллыгына багышланган спортның ишегалды төрләре фестивален оештыру һәм үткәрүгә чыгымнар
сметасы

| Т/с | Оешманың исеме | Чыгымнарның исеме | Күләм күрсәткечләре | 1 берәмлек чыгымы, сум | Барлыгы, сум |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Автозавод районы Территориаль иҗтимагый үзидарәне үстерүгә ярдәм күрсәтү ассоциациясе | Чараны тавыш белән яңгырату хезмәтләре (тавыш аппаратурасын арендалау, алып баручы, сценарий әзерләүче) | 4 сәгать | 3000,00 | 12 000,00 |
| 2. | | Макет һәм баннер ясау | 3м*6м | 5 000,00 | 5 000, 00 |
| 3. | | Бүләкләү продукциясе:<br>1) 1-3 урыннарны алган җиңүче командалар өчен:<br>– 1 урын өчен кубок<br>– 2 урын өчен кубок<br>– 3 урын өчен кубок<br>2) 11 спорт төре буенча 1-3 урыннарны алган катнашучы-җиңүчеләр өчен медальләр:<br>– 1 урын өчен медальләр<br>– 2 урын өчен медальләр<br>– 3 урын өчен медальләр | <br><br><br><br>1<br>1<br>1<br><br><br>19<br>19<br>19 | <br><br><br><br>1 000,00<br>800,00<br>600,00<br><br><br>90,00<br>90,00<br>90,00 | 7 530, 00<br><br><br>2 400,00<br>1 000,00<br>800,00<br>600,00<br><br>5 130,00<br>1 710,00<br>1 710,00<br>1 710,00 |
| 4. | | Басма продукция:<br>– 11 спорт төре буенча 1-3 урыннарны алган җиңүче командалар һәм катнашучы-җиңүчеләр өчен дипломнар | 36 | 15,00 | 540, 00 |
| 5. | | 11 спорт төре буенча 1-3 урыннарны алган җиңүче командалар һәм катнашучы-җиңүчеләр | 60 | 389, 50 | 23370,00 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | өчен призлар фонды сатып алу | | | |
| 6. | | Катнашучылар һәм ярышларның судьялары өчен эчә торган су | 120 | 13,00 | 1 560,00 |
| | | Барлыгы: | | | 50 000,00 |

Смета буенча барлыгы: 50 000 (илле мең) сум 00 тиен.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова